| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЯР БУЕ МОРКВАШЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.10.2020 с. Набережные Моркваши 8

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең
Пустые Моркваши авылында гражданнар җыенын үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Пустые Моркваши авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020нче елның 31нче октябренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Пустые Моркваши авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә риза булырсызмы:

- Пустые Моркваши авылында балалар мәйданчыгы өчен инвентарь сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Пустые Моркваши авылы, Лесная урамы, 2 нче йорт адресы буенча 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И. Х. Гаязов